**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.10.2018 № ПР-271

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2017-2020 елларга Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгын үстерү» программасы турында» 2018 елның 15 маендагы ПР-102 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Авыл хуҗалыгы турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында» 717 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районында авыл хуҗалыгына продукциянең көндәшлеккә сәләтлелегән арттыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 15 маендагы ПР-102 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасының 6 пунктына үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 6. Программаның күләмнәре һәм финанслау чыганаклары.

Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары. Программаны финанслауның күп каналлы принцибы буенча тормышка ашыру планлаштырыла: федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Актаныш муниципаль районы һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына

| Чыгымнар чыганаклары | Финанслау күләме-млн. сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | | |
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| ФБ, РБнан финанслашу | 1436,954 | 325,024 | 402,65 | 352,18 | 357,100 |
| Актаныш муниципаль районы бюджеты (алга таба-ҖБ) | 235,614 | 168,230 | 58,484 | 3,300 | 3,100 |
| Башка чыганаклар (алга таба - БТ) | 181,150 | 22,600 | 52,750 | 52,85 | 52,950 |

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетыны җитәкчесенең 2018 елның 15 августындагы ПР-102 номерлы карары белән расланган «2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында авыл хуҗалыгын үстерү» муниципаль программасы кушымтасына үзгәреш кертергә, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына программаны гамәлгә ашыру өчен бюджет формалаштырганда финанслауны тәэмин итәргә.

5. Программаны үтәүчеләргә үз вакытында һәм тулысынча үтәүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Татарстан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә:http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru. үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев